**ГЛАВА ЧИРПОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422615 с. Чирпы,
ул. Заводская, д.22
тел: 2-91-45

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧИРПЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422615 Чирпы авылы,
Завод урамы, 22 нчы йорт,
тел: 2-91-45

2024 елның 5 сентябре 1 номер

КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмә хакында» Чирпы авыл җирлеге Советының 2023 елның 27 гыйнварындагы 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024елның 08 августындагы 289-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Чирпы авыл җирлеге советы, КАРАР ИТТЕ:

1.«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмә хакында» Чирпы авыл җирлеге Советының 2023 елның 27 гыйнварындагы 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә, түбәндәге редакциядә бәян итеп:

4.6.4. пункт Планнан тыш күчмә тикшерү бары тик прокуратура органнары белән килештереп кенә үткәрелергә мөмкин, моңа 57 статьяның 1 өлешендәге 3 - 5 пунктлары һәм 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә уздыру очраклары керми.

4.9.5. пункт Күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул ителә алмый.

4.7.10 Пункт. Рейд тикшерүе прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа 248 - ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3-5 пунктлары һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12_1 өлешләре нигезендә үткәрелгән очраклар керми.

2.Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3.Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Чирпы**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Р.В. Мышева**